ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта «урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга,» сүзләрен «федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре нигезендә урта һөнәри белемнең уку-укыту программаларын, бакалавриат программаларын, специалитет программаларын һәм магистратура программаларын, федераль дәүләт таләпләренә туры китереп аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын,» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:
«$9^1$. Аспирантурада федераль дәүләт таләпләре нигезендә фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары йомгаклау аттестациясе узган затларга фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертациянең «Фән турында һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте хакында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законга таянып билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә һәм аспирантураны тәмамлау хакында таныклык бирәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 14-ТРЗ